СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

22.02.2019 № 84/5
На № ________ от ____________

# КАРАР

**«Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларның хезмәтенә түләү күләмнәре һәм шартлары турында нигезләмә»гә үзгәрешләр кертү хакында**

«Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 санлы Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 декабрендәге 1320 санлы карары, район уставының 30 маддәсе нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы Советының 2018 елның 23 апрелендәге 25/5 санлы карары белән расланган «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларның хезмәтенә түләү күләмнәре һәм шартлары турында нигезләмә»гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Айлык акчалата бүләкләү билгеләргә:

- муниципаль район Башлыгына 2,4 айлык акчалата бүләкләү күләмендә;

- муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары, контроль-хисап палатасы рәисенә 1,077 айлык акчалата бүләкләү күләмендә.

1.2. 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль берәмлек Башлыгына айлык акчалата түләүләрнең гомуми күләме Татарстан Республикасы министрына айлык акчалата түләүләрнең гомуми күләменнән артып китә алмый».

1.3 «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны даими нигездә биләүче затларның хезмәтенә түләү күләмнәре һәм шартлары турында нигезләмәгә кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнвареннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары Р.И. Закиров

«Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2019 елның 8/15
22.02.2019 ______
санлы карарына кушымта

## Үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы муниципаль берәмлек Башлыгының, муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасарының, контроль-хисап палатасы рәисенең акчалата бүләкләү күләме

| Вазыйфа исеме | Айлык акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Муниципаль берәмлек Башлыгы | 33 948 |
| Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары | 30 552 |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 30 552 |